Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы

Байлангар авыл җирлеге башлыгы

карары

2022 елның 11 ноябре № 21

«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставынының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 23 ноябрենә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Байлангар авылы, Совет урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан Байлангар авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 23 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлегенең Байлангар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Байлангар авылы, Совет урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан Байлангар авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлеге Байлангар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,

- 1 төркем инвалидларыннан;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан);
- 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан;
- 18 яшькә кадәр 3 яки аннан да күбрәк баласы булган аналардан;
- 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала,

900 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-су башнясын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру

- Байлангар авылы мәдәният йортына җиһазлар һәм спорт җиһазлары сатып алу

- янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- Байлангар авылы территориясен төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Совет урамы тыкрыгын төзү һәм ремонтлау; (проект-смета документларын эшләү; материаллар алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- ял итү зоналарын төзү һәм төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыру; Сабантуй бәйрәме уздыру урыны территориясен төзү һәм төзекләндерү; (сәхнә, тамашачылар эскәмияләре, спорт инвентарьларын саклау өчен складны төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү; материал алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- зиратларны карап тоту; (бәдрәф , инвентарлар сатып алу, килешү буенча түләү;

- су кудыру башняларын ремонтлау һәм буяу, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу; (проект-смета документларын эшләү, материал сатып алу, килешү буенча түләү);

- урам утларын карап тоту;( энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Байлангар авылында кышкы-җәйге юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»?

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Халык җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Байлангар авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы И.Ф. Кәримуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО района РТ • БАЙЛАНГАРСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ • ТР КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЙЛАНГАР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ОГРН 1061675010462
ИНН 1623008401